РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

21.04.2021 № 449-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2013 елның 19 сентябрендәге 1195-п номерлы карары белән расланган мәктәпкәчә белем бирүнең белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 2020 елның 5 ноябрендәге 999 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

**1.** Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең “Мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында” 2013 елның 19 сентябрендәге 1195-п номерлы карары белән расланган, мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибенә (2015 елның 31 декабрендәге 1676-п номерлы, 2016 елның 12 маендагы 575-п номерлы, 2017 елның 14 мартындагы 267 номерлы, 2017 елның 29 августындагы 1025-п номерлы, 2018 елның 29 гыйнварындагы 71-п номерлы, 2019 елның 2 сентябрендәге 1020-п номерлы, 2021 елның 29 гыйнварындагы 83-п номерлы карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1.** Тәртипнең 1.3 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ай саен бирелә торган компенсацияне билгеләү өчен гаиләнең җан башына туры килә торган уртача кереме, балага айлык компенсация билгеләү турында гариза бирелгән ай алдыннан алты календарь айга кадәрге соңгы 12 календарь айда гаилә әгъзаларының керемнәре суммасыннан чыгып исәпләнә (алга таба - текст буенча - «хисап чоры»).

**2.** Әлеге карарны “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Җитәкче М.Р. Ишниязов